Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-1**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 15.07.2016 ел №XI-1, 24.07.2017 ел №XX-1, 12.04.2018 ел № XXX-1, 01.04.2019 ел №XLI-1 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кушымтага ярашлы рәвештәүзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсендәге 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 90 маддәсендәге 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2019 елның 24 сентябрендәге
XLV-1 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 маддәнең 1 пунктындагы 8 пунктчасында “хокуклар” сүзеннән соң “аз санлы төп халыклар һәм башкаларның” сүзләрен өстәргә;

2) 6 маддәнең 1 өлешендәге 17 пунктында “, авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү” сүзләрен өстәргә;

3) 8 маддәдә:

а) 1 өлешнең 13 пунктында “территориянең, бирү” сүзләреннән соң түбәндәге сүзләрне өстәргә: “җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы, бирү”, ә “Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә рөхсәтсез алып барылган төзелешне җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата федераль законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрдә билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү (алга таба шулай ук - билгеләнгән таләпләргә туры китерү),” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлектәге 26 пунктны өстәргә:

“26) җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм аның өчен билгеләнгән «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан чаралар үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру”;

4) 27 маддәдә:

а) 10 пунктында “район Советы депутаты” сүзләреннән соң “яисә күрсәтелгән затларга карата җаваплылыкның башка чараларын куллану” сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 10.1, 10.2 пунктларны өстәргә:

“10.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән район Советы депутатына, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү дәрәҗәсе алай ук мөһим булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү (искәртү);

2) депутатны вазыйфадан азат итү, район Советында вазыйфа биләүдән мәхрүм итү;

3) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) вәкаләтләре туктатылганчы, район Советында вазыйфа биләүдән тыю;

5) вәкаләтләре туктатылганчы, даими нигездә вәкаләтләр башкарудан тыю".

10.2. Депутатка карата әлеге маддәнең 10.1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә. ";

5) 43 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктлар өстәргә:

"4. Җирле үзидарәнең үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат биргән сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр бу мәгълүматларны бозу алай ук мөһим дәрәҗәдә булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, аның вәкаләтләре вакыты беткәнче, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән мәхрүм итеп, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфадан азат итү;

3) вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан вәкаләтләре вакыты беткәнче мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре вакыты туктатылганчы вазыйфалар биләүне тыю";

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

"5. Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына әлеге маддәнең 4 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә";

6) 46 маддәдә:

а)1 өлешендә:

3 пунктның өченче абзацында ", авылара территориядә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирә" сүзләрен өстәргә;

5 пунктның уникенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктның унөченче абзацында "хокуклары" сүзеннән соң "җирле аз санлы төп халыклардан һәм башкалардан" сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлешендә:

15.1 пунктта "Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә рөхсәтсез алып барылган төзелешне җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итү, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата федераль законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрдә билгеләнгән капиталь төзелеш объектларын

реконструкцияләү (алга таба шулай ук - билгеләнгән таләпләргә туры китерү),”сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 28 пунктны өстәргә:

“28) җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм аның өчен билгеләнгән «Җылылык белән тәэмин итү турында» Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итү схемасында билгеләнгән җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан чаралар үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру”.

7) 50 маддәнең 1 өлешендәге 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасында вазыйфаларны бүлә, район Башкарма комитетының муниципаль хезмәткәрләрен һәм башка хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана”;

8) 87 маддәдә:

а) 1 пунктта “Россия Федерациясе бюджет законнары һәм башка норматив законнар” сүзләрен “нигезләмәләр” сүзе белән алмаштырырга, түбәндәге сүзләрне өстәргә: “,физик затларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан гавами норматив йөкләмәләр һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләр бирә торган хокукый актлар, шулай ук бюджеттан акчалар бирү турында дәүләт (муниципаль) контрактлары, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү”;

б) 2 пунктта “бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Эчке муниципаль финанс контроле район башкарма комитеты органнары булган муниципаль финанс контроле органнарының контроль эшчәнлеге булып тора.”;

9) 90 маддәнең 2 өлешендә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Район Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында район Советы карары дәүләт теркәве узганнан соң рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы” нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының “Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар” (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф, челтәр басмасы сыйфатында теркәлү: Эл. N ФС77-72471, 05.03.2018) порталында рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керәләр”.